**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

Министерство образования и науки Республики Татарстан

Исполнительный комитет муниципального образования "Лениногорский муниципальный район" Республики Татарстан

МБОУ "Гимназия №11 г. Лениногорска"

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: [illegible]53DD1AA3
Владелец: Шарифуллина Гульнара Тагировна
Действителен с 03.07.2023 до 03.10.2024

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Кафедрой татарского языка | Заместителем директора по национальному образования | Директор МБОУ "Гимназия №11 г.Лениногорска" |
| ______________ Касимова Л.А. | ______________ Самигуллина В.М. | ______________ Шарифуллина Г.Т. |
| Протокол №1 | Протокол № 1 | Приказ № 179-ОД |
| от "28" 08 2023 г. | от "28" 08.2023 г. | от "29" 08.2023 г. |

# Рабочая программа

учебного курса
«Татарское народное устное творчество (фольклор татарского народа)»
для 5 класса основного общего образования
для образовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке
на 2023-2025 учебный год

Составитель: Закирова Залифа Мунависовна

Учитель родного языка и литературы

Лениногорск 2023

## **Аңлатма язуы**

Хәзерге вакытта Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән татар әдәбиятын укыту программаларында һәм дәреслекләрдә татар халык авыз иҗатын өйрәнүгә бик аз вакыт бирелә. Билгеле, бу әдәбиятка караган дәресләрнең гомуми саны аз булу белән аңлатыла. Урта мәктәптә татар халык авыз иҗаты урта звенода уку елы башында ук өйрәнелә. Һәм татар халык авыз иҗаты байлыгын күз алдына китерү өчен генә дә бу сәгатьләр саны җитәрлек түгел.

Күренекле язучы, әдәбият белгече, М.Горький инде узган гасырның беренче яртысында, ил күләмендә язучылар союзы оешкан чорда ук үзенең бер чыгышында: “Сүз сәнгатенең башы фольклорда” дигән фикерне әйтә. Чыннан да матур әдәбият үзенең эчтәлеге, формасы, жанрлар һәм образлар системасы формалашу ягыннан да фольклорга нигезләнә. Шуңа күрә мәктәп чорыннан ук укучыларны әдәби әсәрне фольклорга нигезләнеп аңларга өйрәтү дә бик мөһим.

Шул ук вакытта халык авыз иҗаты мирасы белән танышу укучы күңелендә туган төбәккә мәхәббәт уяту, патриотизм хисләре тәрбияләү, халкыбызның милли йолаларын, этнографиясен өйрәнү өчен дә мөмкинлек бирә. Халык иҗаты әсәрләре, бала күңелендә кечкенәдән әдәплелек, тәүфикълылык, намуслылык кебек югары әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә нигез булып тора.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү эшендә фольклор мөмкинлекләреннән файдалану - туган нигезгә, төбәккә, халыкка, аның гореф – гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияли. Моңа ирешү юлында дәрестән тыш чаралардан иң уңышлысы – халык иҗатын түгәрәк кысаларында өйрәнү.

**Максат.** Татар халык авыз иҗатын, аның жанрларын, образлар системасын, поэтик үзенчәлекләрен өйрәнү аша укучыларны рухи яктан бай, белемле, иҗади сәләтле, югары мәдәниятле, камил, конкурентлыкка сәләтле, үз иленең патриотлары булган шәхес итеп тәрбияләү.

Бу максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- Халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышу, бу өлкәдә эшләүче галимнәр хезмәтен һәм оешмалар эшчәнлеген өйрәнү;
- Халык авыз иҗаты жанрларын, образлар системасын, тематикасын һәм поэтик үзенчәлекләрен өйрәнү аша укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә сәләтле һәрьяктан камил шәхес итеп тәрбияләү;
- иҗади омтылыш, халык авыз иҗаты үрнәкләрен, йолаларны өйрәнеп, аларга карата милли горурлык хисләре тәрбияләү.

## Әкият жанры турында

Реаль һәм фантастик алымнар белән сурәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша халыкның үткән тормышын, киләчәккә карата хыял һәм омтылышларын чагылдыручы чәчмә халык авыз иҗаты әсәрләре әкиятләр дип атала. Халкыбызның авыз иҗатында әкиятләр иң бай һәм мөһим жанрларның берсе булып тора.

Татар халык әкияләрен шартлы рәвештә өч төркемгә бүләләр: хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы әкиятләр һәм тормыш-көнкүреш әкиятләре.

Татар халык әкиятләре арасында хайваннар турындагы әкиятләр күп түгел дияргә була. Мондый әкиятләрнең төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре, кошлар һ. б. Хайваннар турындагы әкиятләрдә төрле хайваннарга төрлечә бәя бирелә: ат – һәрвакыттагыча, эшчән һәм кешенең якын дусты; кәҗә – тапкыр, бүре – усал һәм аңгыра, арслан – көчле, төлке – хәйләкәр, аю – авыр табигатьле һ. б. Хайваннар турындагы әкиятләрдә иң еш очрый торган киек – төлке. Аннан кала аю һәм бүре. Төлке барлык әкиятләрдә да диярлек хәйләкәр, алдакчы, ялагай итеп сурәтләнә. Аю, бүре – тупас, ахмак буларак тасвирлана.

Хайваннар турындагы күпчелек әкиятләр сыйнфый җәмгыять шартларында төрле төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерә. Әкият эчтәлегендәге бу хакыйкатьне балаларга ача белү, төшендерү кирәк. Бу төр әкиятләрнең тагын бер мөһим сыйфаты бар: аларда аллегория ярдәмендә

гомумән кешеләргә хас кимчелекләр дә тәнкыйть ителә. Бу очракта хайваннарның гадәтләре, йөреш-кыланмышлары кешеләрдә очрый торган тискәре сыйфатларны күрсәтү өчен файдаланыла. Әкиятләрдә ялкаулык, эш сөймәү кебек сыйфатлар аеруча көчле ирония белән сурәтләнә, хезмәт сөймәүчеләр хурлыкка калдырыла, аларга карата тискәре караш тудыра. Яхшылыкның кадерен белмәү, игелекне оныту кебек сыйфатларны да халык кискен гаепли. Кыскасы, бу төркем әкиятләрдә халык әхлагы, аның кагыйдәләре чагылыш таба.

Тылсымлы әкиятләрнең үзәгендә уңай образ – батыр, акыллы, кулыннан һәртөрле эш килә торган егет образы тора. Халыкның көче һәм аның тапкырлыгы менә шул егет образында бирелә. Ул патша, дию пәриләре, аждаһалар яки башка шуның кебек кара көчләргә каршы көрәштә һәрвакыт җиңеп чыга. Әкият герое хезмәт халкының иҗтимагый, әхлакый һәм эстетик идеалларын чагылдыра. Аңа акыл иясе картлар, курку белмәс дуслары, тапкыр һәм сөйкемле сылу кызлар, төрле серле әйберләр, кешегә ияләшкән кыргый хайваннар булышалар.

Тылсымлы әкиятләрнең бер өлеше аталар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләүдән башланып китә. Карт ата үләр алдыннан балаларына васыять итеп калдыра ("Һөнәрле үлмәс", "Юләр угыл", "Өч ул" һ. б.). Аталарның васыятен тотмаган, икенче төрле итеп әйткәндә, өлкәннәрнең тормыш һәм хезмәт тәҗрибәләре белән хисаплашырга теләмәгән әкият геройларын халык гаепли, аларны бәхетсезлеккә дучар итә. Аталарының васыятен, киңәшен тоткан уллар исә әкиятләрдә мактала, алар юлларында яңадан-яңа уңышларга ирешәләр.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә ялкаулык, саранлык, куркаклык һәрвакыт кешеләрдәге иң начар сыйфатлар буларак күрсәтелә.

Татар халкы әкиятләрендә хезмәт ияләре – акыллы, зирәк, ә комсыз байлар исә надан булып сурәтләнә. “Кәкре каен” әкиятендә халыкның зирәклеге комсыз байларның наданлылыгына каршы килә.

# Мәкальләр турында

*“Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә һәм дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип йөртелә”.*

*Нәкый Исәнбәт*

Мәкальләр – халык авыз иҗатының кыска төре. Алар бик борынгы заманнардан бирле яшәп киләләр, телдән телгә күчеп таралар һәм хәзерге вакытта да бик актив иҗат ителәләр. Мәкальләр күләме белән кыска һәм тирән мәгънәле, тәмамаланган фикерне аңлата торган, рифмага салып әйтелгән җор сүзләр була. Алар халыкның күпьеллык тәҗрибәсе нигезендә сыналган эшнең нәтиҗәсе буларак туалар. Дөньяда телсез, җырсыз һәм моңсыз халык булмаган кебек, мәкальсез халык та юктыр, һәрбер халык үз телендә мәкальләр кыстырырга ярата, үз телен аның белән бизи, төзи. Һәркайда, һәр халыкта үз мәкальләренә хөрмәт бар, аларга ышану, таяну бар. Безнең халыкта да шундый ук хәл: татар сөйләшкәндә сүз арасында урынына карап, фикерне куәтләү өчен кыска гына һәм килешле генә итеп, хикмәтле бер мәкаль әйтеп куя.

Мәкальләр зур өч төркемгә бүленәләр:

1) хезмәт һәм табигать дөньясы, аны тану, сынау, үзгәртү турындагы мәкальләр;
2) гаилә тормышы, тән тереклеге турындагы мәкальләр;
3) тарихи һәм иҗтимагый һәм әхлакый мәкальләр.

Мәкальләрнең түбәндәге әһәмиятләре билгеләнә:

1) мәкальләрнең, авыз иҗаты буларак, аталар сүзе яки халык хикмәте булуы;
2) мәкальнең безне иҗтимагый фикергә ия итүе;
3) тел байлыгы булу ягыннан;

4) мәкальләрнең хикмәт, тәҗрибә яки сүз материалы булып кына калмыйча, сәнгатьәсәре булуында;
5) мәкальләр халыкның культура һәм иҗтимагый тарихын, этнографичсен өйрәнү ягыннан күп кенә материаллар бирә алалар;
6) мәкаль халык рухын өйрәнү ягыннан кызыклы һәм әһәмиятле булуы;
7) мәкальләрнең (һәм шулай ук әйтемнәрнең дә) фикер оештыручы трибун булуында;
8) тәрбияви әһәмияте;
9) мәкальләрнең аңны һәм тормышны үзгәртү коралы булуында.

## Табышмаклар турында

Табышмаклар – мәкальләр, әйтемнәр, сынамышлар белән бергә, - халыкның афористик иҗаты составына керәләр. Исеменнән үк аңлашылганча, алар тыңлаучылар алдына асылы читләтеп әйтү аша белдерелгән билгесез әйбер яки күренешне эзләп табубурычын куялар. Читләтеп әйтү өчен нинди алымнар һәм чаралар куллануга карап, фольклор фәнендә табышмаклар метафорик, сорау, арифметик дип аталган төп өч төргә бүлеп йөртәләр.

Төзелеше буенча табышмаклар шигъри һәм чәчмә формада булырга мөмкин. Табышмак һәрвакыт ике өлештән – шигъри сурәттән һәм аның җавабыннан торырга тиеш. Җавап өлешен югалтса, ул табышмак буларак яшәвеннән туктый.

Табышмаклар уен-ял вакытларында, шаярып-көлешеп әйтелсәләр дә, аларның әһәмияте дөнья мәшәкатьләрен онытып торырга, вакытны күңелле үткәрергә ярдәм итү белән генә чикләнми. Шул күңел ачу процессында кешеләр, табышмакка җавап эзләп, зиһеннәрен үткерлиләр, әйберләрне чагыштырып карарга, аларның яңадан-яңа сыйфатларын ачарга өйрәнгәннәр. Поэтик яктан гаҗәп матур, тапкыр сүрәтләр халыкның күңелендә соклану, сөенеч хисләре уяткан, эстетик ләззәт биргән.

Табышмак жанры чынбарлыкның аерым бер өлкәсен чагылдыра. Ул тормыштагы коекрет әйберләрне һәм күренешләрне тасвирлый, карап торуга гади генә әйберләрнең дә гаҗәп матур шагъри сурәтләрен тудыра.

Өй башында дранча,
Дранча саен бер акча. **(Тактадагы ботак эзе)**
Ишекле-түрле яшь килен йөри. **(Себерке)**

Үзе сурәтли торган әйберне һәм күренешләрне табышмак реаль тормышның төрле өлкәләреннән ала. Шулай да аларның зур күпчелеге авыл кешесенең хезмәтенә багышланган. Аннары гомумән кешенең практик эшчәнлегенә мөнәсәбәте булмаган табышмакларны күрсәтүе читен. Киек хайваннар һәм кыргый үсемлекләр турындагы әсәрләрне алып карасак та, алардабу нәрсәләрнең тышкы сыйфатлары гына тасвирланмавын, бәлки хуҗалык өчен әһәмиятле булулары, кешегә файдалы яки зарарлы якларга әйтелүен күрәбез.

Табышмакларның кешеләр үз куллары белән җитештерелгән көнкүреш әйберләрен сайлап алалар: Кояш – тегермән ташы; Ай – калач; ел һәм көннәр – каз һәм аларның бәбкәләре һ.б. Халык очсыз-кырыйсыз күк йөзен, ай һәм йолдызлары белән бергә, бик тапкыр гына авыл өендәге мич эченә “төшереп утырта”:

Мич, мич, мичәкәй,
Мич эчендә чичәкәй;
Чичәкәйдә бер бәлеш,
Түгәрәге бәрәмеш.

Татар халкы табышмакларында иген игү процессы караганнары да күп. Аларда җир сөрү, тырмалау, орлык чәчү, игеннәрнең үсүе, аларны җыеп алу, ашлыкны эшкәртү – барысы да киң чагылыш таба.

Табышмаклар тематик төрлелек бик зур. Аларда күк җисемнәре, җир-су, табигать күренешләре, кием-салым, савыт-саба, аш-су, культура-көнкүрешкә караганнарын да табарга була. Кыскасы, бу төр татар халык иҗатында җирдәге һәм күктәге барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләр сурәтләнүен күрә алабыз.

**Түгәрәк эшчәнлегенең төп эчтәлеге:**

1. Беренче чиратта, түгәрәк эшчәнлеге мәктәп дәреслекләрендә тәкъдим ителгән фольклор үрнәкләрен тирәнтен өйрәнүне, өстәмә мисаллар белән ныгытуны, ягъни, фәннилек принцибын гамәлгә ашыруны күздә тота.
2. Икенчедән, халык иҗаты мирасын, дәрестән тыш тәрбия чараларында өйрәнүне планлаштыра.
3. Укучыларның халык авыз иҗатының бүгенге шартларда яшәешен күзәтү һәм алдагы буыннарга дәвам итүгә катнашу мөмкинлеген үстерүне максат итеп куя.

**Түгәрәк утырышларында белем һәм тәрбия бирү формалары:**

- Укытучы сөйләве;
- Әңгәмә;
- Интервью;
- Рольле уеннар;
- Читтән торып сәяхәт итү (татар халкының төрле этник төркемнәренең этнографиясенә нигезләнеп);
- Әдәби кунакханә
- Фотоальбомнар төзү
- Газеталар чыгару
- Викторина оештыру
- Информантлар белән эшләү
- Видеоматериаллар туплау һәм аларны өйрәнү
- Конкурсларда, конференцияләрдә катнашу

**Белем һәм тәрбия бирүнең максат һәм бурычлары.**

(һәр уку елына)

| Уку елы | Максатлар | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1 | -Халык авыз иҗатына хас төп үзенчәлекләрне, фольклор берәмлекләрен, жанр төрлелеген, бу өлкәдә эшләүче галимнәр хезмәтен өйрәнү. | -Фольклор турында төшенчә булдыру, татар халык авыз иҗатының милли үзенчәлекләрен өйрәнү;<br>-Укучыларнын күзаллавын киңәйтү,халык иҗатының бүгенге көндә дә яшәвен аңлату;<br>-Үз халкың, аның үткәне һәм бүгенгесе белән горурлану хисләре тәрбияләү. |
| 2 | Фольклор һәм этнография бәйләнешен өйрәтү. Күпмилләтле Татарстанда яшәүче халыкларның фольклорындагы уртак һәм аермалы якларны өйрәнү | -Укучыларга халык иҗатының этнография белән тыгыз бәйләнештә булуын аңлату. Этнографик эволюцияне күрсәтү. Татарстанда яшәүче башка халыклар фольклоры турында мәгълүмат бирү.<br>-Укучыларның сөйләм телен баету;<br>-Укучыларны, иҗади сәләтләрен үстерү. Фольклорга нигезләнеп, иҗат эшенә җәлеп итү. |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Халык авыз иҗатының язма әдәбиятка йогынтысын өйрәнү | -Фольклорның язма әдәбиятка нигез булуын аңлату.<br>-Әдәби әсәр текстыннан фольклоризмны табу күнекмәләрен үстерү;<br>- чыганаклар белән эшләү күнекмәләрен камилләштерү.<br>-мәктәп, түгәрәк һәм гаилә эшчәнлеген тыгыз элемтәдә алып баруга ирешү;- |

**Белем һәм күнекмәләр.**

(һәр уку елына)

| Уку елы | Белем | Күнекмәләр | Тикшерү |
|---|---|---|---|
| 1 | - Халык авыз иҗатының эпик төренә керүче әкият, дастан, риваять, легенда, мәзәк, лирик төренә караган җыр, мөнәҗәт, лиро-эпик төренә караган бәет жанрларын, афористик иҗат төрләрен: мәкаль, әйтем, табышмак, | -Чыганаклар белән эшләү күнекмәләрен үстерү;<br>Сорауларга тулы җавап бирә белү,<br>-Фольклор әсәрләрен анализларга өйрәнү | -әңгәмә<br>-викторина<br>-рольле уеннар аша фольклор текстларын ни дәрәҗәдә аңлауларын ачыклау<br>- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | алкышларны өйрәнү, аларның жанрлык сыйфатларын аера белү.<br>Татар фольклорын өйрәнүче галимнәр эшчәнлеге белән танышу. | | |
| 2 | -Татар фольклорының этнография белән әйләнешен өйрәнү. Татар милли костюмы, йорт-җир, ризык, бизәнү әйберләре хакында мәгълүмат булдыру. Йола иҗатының кеше тормышындагы ролен аңлату.Фольклорда уртаклык мәсьәләләре хакында мәгълүмат бирү. | -Сәнгать төрләрен аера белү,<br>-Кунакчыл була белү, | -альбомнар туплау<br>-конкурс, конференцияләрдә катнашу. |
| 3 | -Халык авыз иҗатының язма | Текстлар, чыганаклар | -Әдәби кунакханә<br>-газета чыгару |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әдәбиятка йогынтысын ачыклау. Фольклоризм төшенчәсен аңлату. | белән эшләү күнекмәләрен ныгыту, әдәби әсәрдән фольклор материалын аерып ала белергә өйрәнү. -Эзләнү нигезендә халык авыз иҗатының бүгенге көндә нинди формаларда яшәвен күзәтү. | -рольле уеннар Конференциядә чыгыш ясау. |

## Программаның укыту-тематик планы

| № | Темалар | сәгатьләр | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Нәрсә ул фольклор? | | | |
| 2 | Халык авыз ижатына хас төп үзенчәлекләр. Телдән иҗат ителү. Вариантлылык. | | | |
| 3 | Мәктәп китапханәсенә экскурсия. Фольклорга караган китаплар белән танышу. | | | |
| 4 | Мифлар. Мифлар турында төшенчә. Аларның килеп чыгышы, төрләре. | | | |
| 5 | «Җил иясе җил чыгара», миф | | | |
| 6 | «Тавык», миф | | | |
| 7 | Татар халык әкиятләре. Әкиятләрнең төрләре. Тематикасы. Образлар системасы. Әкиятләрнең бүгенге көндә яшәеше. | | | |
| 8 | Әкиятләрдә тел-стиль үзенчәлекләре | | | |
| 9 | «Хәйләкәр төлке» әкияте. | | | |
| 10 | «Өч кыз» әкияте | | | |
| 11 | «Ак бүре» әкияте | | | |
| 12 | «Ак бүре» әкияте буенча әңгәмә | | | |
| 13 | “Иң яхшы әкиятче”. Әкият сөйләү. | | | |
| 14 | Өйрәнелгән әкиятләр буенча викторина уздыру | | | |
| 15 | Яшь әкиятче бәйгесе. | | | |
| 16 | Татар халык әкиятләрен карау | | | |
| 17 | Риваятьләр турында төшенчә | | | |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | «Шәһәр нигә Казан дип аталган» | | | |
| 19 | Легендалар турында төшенчә | | | |
| 20 | «Зөһрә кыз» легендасы | | | |
| 21 | «Кәккүк каян барлыкка килгән» легендасы | | | |
| 22 | Легенданың һәм риваятнең үзенчәлеге. | | | |
| 23 | Татар халык авыз иҗатының бер төре – табышмаклар. Табышмакларның төрләре | | | |
| 24 | Табышмаклар уйлап чыгару | | | |
| 25 | «Кем тизрәк?» уены. | | | |
| 26 | Табышмак - әкиятләр | | | |
| 27 | Аталар сүзе - халыкның үзе. Мәкальләр | | | |
| 28 | Әйтемнәр. | | | |
| 29 | Татар халык җырлары. Татар халык җырларының төрләре | | | |
| 30 | Йола, уен – бию җырлары | | | |
| 31 | Тарихи җырлар | | | |
| 32 | Лирик җырлар | | | |
| 33 | Кыска җырлар | | | |
| 34 | Татар халык авыз иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнгән галимнәр эшчәнлеге белән танышу. | | | |
| 35 | Йомгаклау. | | | |

## Программанын эчтәлеге

1. **Кереш дәрес. Танышу**. Хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен аңлату.

*Теория.* Ел буена булачак план, эш барышы белән танышу.

2. **Халык авыз иҗатына хас төп үзенчәлекләр.**

*Теория.* Халык авыз иҗаты турында төшенчә бирү. Халык әдәбияты, халык авыз иҗаты, фольклор терминнарын аңлату.

*Практика.* Фольклорда синкретизм күренеше. Коллектив иҗат нәтиҗәсе булу. Телдән иҗат ителү. Вариантлылык.

3. **Мәктәп китапханәсенә экскурсия.**

*Теория.* Фольклорга караган китаплар белән танышу.Халык авыз иҗаты җыентыклары, хрестоматияләр, дәреслекләрне эзләп табу. Укучыларга дәреслекләр белән эшләү тәртибе турында сөйләү.

4. **Татар халык әкиятләре.**

*Теория.* Халык авыз иҗатында әкият жанры, аның төрләре. Хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы әкиятләр, тормыш-көнкүреш әкиятләре.

*Практика.* Әкиятләрне уку. Тематикасын ачыклау. Әкиятләрдәге мифологик образлар белән танышу. Дию, Убырлы, Үзе бер карыш, сакалы биш карыш, Юха елан һ.б. Тылсымлы әкиятләргә хас әверелү һәм йоту мотивлары турында сөйләшү. Әкиятләргә нигезләнеп эшләнгән мультфильм һәм кинофильмнар карау, алар турында фикер алышу. Халык әкиятләренә нигезләнеп, укучыларның әкият иҗат итүләре.

5. **Фольклор мирасында риваятьләр.**

*Теория.* Риваятьләр, аларның төрләре. Топонимик һәм тарихи риваятьләр.

*Практика.* Укучылардан аларның әби-бабайлары яшәгән авыллардан топонимик риваятьләр язып алып килергә кушу һәм аларны укып, фикер алышу, фотолар карау.

6. **Легендалар, аларның төрләре.**

*Теория*. Легендаларның риваятьләрдән аермасы һәм уртак яклары.

*Практика*. “Зөһрә кыз”, “Алып кешеләр”, “Кеше гомере ничек корылган?”, “Ана йөрәге” легендалары белән танышу.

7. **Татар халык җырлары**

*Теория.* Татар халык җырлары: йола җырлары, уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик җырлар.

*Практика.* Җырларның тематик төркемнәре. Җырлардагы традицион образлар. Бүгенге көндә дә популяр булган халык җырлары. Халык җырларының автор җырларыннан аермасы.

8. **Аталар сүзе- акылның үзе.** Халык иҗатының афористик төрләреннән мәкальләр һәм әйтемнәр.

*Теория.* Мәкаль һәм әйтемнәргә билгеләмә. Аларны өйрәнү. Н.Исәнбәт төзегән “Татар халык мәкальләре” өчтомлыгы.

*Практика.*Мәкаль-әйтемнәрнең тематик төркемнәре. Күрсәтелгән темалар буенча мәкальләр әйтү. Мәкальләр буенча викторина сорауларына җавап бирү.

9. **Табышмак әйтәм - уйлап тап.**

*Теория.* Халык авыз иҗатында табышмаклар. Аларның баланың логик фикерләвен үстерүдәге әһәмияте.

*Практика.* Табышмакларның төрләре. Табышмаклар әйтешү.

10. **Татар халык авыз иҗатын өйрәнгән галимнәр эшчәнлеге белән танышу.**

*Теория.* Татар фольклорын өйрәнү тарихы белән танышу. Татар фольклористикасы тарихында тирән эз калдырган күренекле галимнәр К.Насыйри, Х. Ярми, И.Надиров, Х.Мәхмүтов, Ф.Урманчеев, М.Бакиров, А.Садекова, К.Миңнуллин, Л.Җамалетдинов, Р.Ягъфәров, Ф.Әхмәтова-Урманче һ.б. хакында мәгълүмат бирү.

*Практика* Татар фольклорын җыю, бастырып чыгару, фәнни өйрәнү эшенә зур өлеш керткән язучылар һәм шагыйрьләрдән, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, М.Мәһдиев, Э.Касыймов һ.б. эшчәнлеге.

*Теория.* Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтындагы халык иҗаты секторының эшчәнлеге 13 томлык Татар халык иҗаты җыйнамасы.

*Практика.* Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы Традицион мәдәниятне үстерү үзәге белгечләре эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү.

11. **Йомгаклау. Ел дәвамында өйрәнгән материалга йомгак ясау.**

Лист согласования к документу № 60 от 16.04.2024
Инициатор согласования: Шарифуллина Г.Т. Директор
Согласование инициировано: 16.04.2024 10:45

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарифуллина Г.Т. | | Подписано 16.04.2024 - 10:45 | - |